ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16. 02. 2021 г.Мензелинск № 45

**Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль район Башкарма комитетының 2014 елның 11 апрелендәге "Төзелеш, архитектура һәм ТКХ өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" 336 нчы номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында**

2020 елның I яртыеллыгы өчен Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджет үтәлеше нәтиҗәләре буенча финанс, казна һәм салым органнарының республика киңәшмәсе Беркетмәсенең 12 нче пунктын һәм 08.08.2020 елдагы ПР-167 номерлы Беркетмәсе нигезендә, 2020 ел ахырына кадәр финанс, казна һәм салым органнары бурычларын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов вәкиллеге астында, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 1. 2 санлы Кушымтаны 2.6 пункты 10 нчы пуктчысы белән тулыландырырга:

- "салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пеня, штрафлар, процентлар, Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турында законнарына тәңгәл рәвештә түләнергә тиешле процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычларның булмавын раслаучы салым органы белешмәсе".

2.Әлеге карар рәсми төстә басылырга тиеш.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Җитәкче К.Р. Нәҗмиев